



# Каенавыл: халкыбызның йолалары, гореф-гадәтләре, үзенчәлекләре буенча юлкүрсәткеч (путеводитель)










Әдүт, Нурисафа Саликовлар кызлары Фәнизә белән

2023



Каенавыл халкының 97% ыннан күбрәген башкортлар һәм татарлар тәшкил итә.

“Һәр чәчәкнең – үз исе,

Һәр халыкның – үз төсе”, ди татар халык мәкале.

Борынгы бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр, йолалар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәртелеп, гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан әти-әнигә, әти-әнидән балаларга тапшырылып килә. Алар кешегә тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнегергә ярдәм итә. Балалар, яшьләр милли бәйрәмнәрдә, чараларда катнашып, якыннарына, әйләнә-тирәдәге халыкка гына хас булган гореф-гадәтләрне өйрәнә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, тәрбия ала. Милли хисләр формалаша, милли горурлык хисе уяна.

Йолалар, гореф-гадәтләр үзгәрә. Күпмеседер онытыла. Сәбәпләрнең берсе – тормыш-көнкүреш шартларының үзгәрүе. Халкыбызның, авылыбызның шундый берничә йоласы, гореф-гадәте белән өлкәннәр истәлекләренә таянып танышырга чакырабыз.

Юлкүрсәткеч Каенавылда яшәүче халыкның гореф-гадәтләре, йолалары турындагы истәлекләрне саклап калу, авылның игътибарга лаек урыннарын күрсәтү максатыннан эшләнелде.

## Корбан гаете



Каенавыл мәчете

Авылыбыз уртасына бик күркәм булып мәчет урнашкан. Анда укулар, хәйрия ашлары һәм башка чаралар уздырыла. Шуларның берсе – мөселманнар тарафыннан олылап үткәрелә торган Корбан гаете. “Сугыштан соңгы авыр еллар. Туйганчы икмәк ашау көн саен тәтеми. Конфет, прәннек турында әйтеп тә торасы юк. Мөселман халкы Корбан гаете бәйрәмен зурлап үткәрә. Һәр өйдә коймак, чәк-чәк пешерелә. Чәк-чәк ак оннан түгел, авыл тегермәнендә тарттырылган бодай оныннан. Балалар да бу бәйрәмне ярата, көтеп ала. Алар, өй саен кереп, тәм-том җыеп йөриләр, капчыклары тулгач, бергә җыелып сыйланалар. Балалар елга бер генә була торган бу бәйрәмне чәк-чәк җыя торган көн дип көтеп алалар иде. Олылар шулай балаларның авыр балачакларын ямьләндерергә теләгәннәрдер, күрәсең”, дип искә ала олылыр.





Каенавыл балалары һәм авыл күренеше. 1950нче еллар башы



Арткы фонда: Уен тау



Бөек Ватан сугышы ветераны
Ишманов Барый абый белән тормыш иптәше Вәрәкыя апа

**Уен тау**

Авыл кырыенда берничә чакырымга сузылган тау бар. Бу тауны Уен тау дип йөртәләр хәзер дә. Күрше авыллар: Кодаш, Байавыл, Сүҗдегә якын ул. Яшьләр кичен шунда җыелып җырлы-биюле уеннар уйнаганнар, зур таган да булган. Әлбәттә, яшьләрнең очрашу, танышу урыны да булган бу тау. Бөек Ватан сугышы ветераны мәрхүм Ишманов Барый абый (Кодаш егете) хатыны Вәрәкыя апа (Сүҗде кызы) белән шул тауда очрашып таныштык, дип сөйли иде. Аның әйтүе буенча, анда эчеп килгән егетләр булмаган. Бары да дус. Иң мөһиме алар өчен – матур итеп ял итү булган.

## Кантуган чишмә



Кантуган чишмә

Халкыбызда сакланган гореф-гадәт – чишмәләрне изге урын итеп саклау.

Безнең авыл чишмәләре белән дә дан тота: Акбалчык, Мәкәли, Баткак, Шалтырама, Завад, Бигәнби һәм башкалары. Авылдан ерак түгел Кантуган чишмә ага. Суы нинди салкын елларда да туңмый. Элек басуга печәнгә барамы, ураккамы, җимеш җыяргамы – шушы чишмә аша узган авыл халкы. Эшләп арып кайтканда, суын эчеп, сусауларын басканнар. Исемен дә ике төрле аңлаталар: беренчесе – "кан туа", димәк көч арта, икенчесе – "кан туган", русча әйтсәң - "кровная родня". Чишмәгә төкерергә ярамый, пычрак әйберләрне анда юу тыела, дип элек-электән олылар әйтүеннән беләбез. Табигатькә сакчыл караш халыкта шулай тәрбияләнгән.



Кантуган чишмә буендагы помидор түтәлләре янында. 1950нче еллар башы

Кантуган чишмә суы авыруларны савыктыра, хәлләрен җиңеләйтә, ди авылның аксакаллары. "Сугышка китәр алдыннан егетләр, чишмә янына килеп, аның белән саубуллашалар иде", дип искә ала авылдашыбыз Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Мәсгут абый Имашев. Хәзер дә чәйгә дип күп кенә авылдашларыбыз чишмәдән су ташый. Күтәреп күп алып кайтып булмаганга я җиңел машинада, я мотоциклда, я велосипедта баралар күбесе.



1958 ел



1968 ел

## Пумич

Халкыбызда күмәк хезмәтнең бер төре булган өмәләр бик борынгыдан билгеле. Алар күптөрле: каз өмәсе, бура күтәрү, печән чабу, йорт салу, яз көне өй юу, авылларда урамнарны, каберлекләрне чистарту, төзекләндерү һәм башкалар.

“Безнең якта берәр зур эш булса, мәсәлән, йорт салырга, урак урырга, каз йолкырга, күпләп җыелып, бер-берсенә ярдәм итеп эшләгәннәр. Мондый эшне “пумич” дип атыйлар иде. Үзебезчә әйтсәк: “ызба күтәрмәгә пумич”, “урак пумич”, “каз йолку пумич”. Булышырга күршеләр генә түгел, башка авылдашлар да килгән. Эшләгән өчен беркем дә акча алмаган. Бирергә акча да булмагандыр инде. Ә эштән соң хуҗа барысын да сыйлаган, күңел ачканнар”, дип сөйли өлкәннәр. Димәк, пумич – бер-береңә ярдәм итү йоласы.



1967 ел



1959 ел

**Кунаклашу**

Халкыбызның элек-электән килгән гаилә йолалары да бар. Шуларның берсе – кунаклашу.

Олы яшьтәге авылдашларыбыз истәлеге: “Әби-бабайларыбыз кунакка ерак, күрше авыллардан туганнарын, дусларын чакырганнар. Гадәттә, кунакка берничә көнгә ат белән барганнар. Кунак каршы алуның үз кагыйдәләре булган. Хуҗа (ир кеше) аларны, капка төбенә чыгып, көтеп каршы алган, кунакларның атын туарган, туйдырган. Кич белән еракtan килгән кунаклар янына авылдашларын да чакырганнар. Өйдә идән уртасында ашъяулык. Кунаклар идәнгә ашъяулык тирәсенә утырганнар. Һәрберсенә тезҗәймә (салфетка) биргәннәр, аны тез өстенә салганнар. Иртәгесен кунакларга мунча якканнар. Кунакларны хөрмәтләп, авылны чыкканчы озатып барганнар. Гадәттә, соңыннан хуҗаларны үзләрен җавап итеп кунакка чакырганнар. “Кунак ашы – кара каршы”, - дип юкка гына әйтми халык”. Мондый кунакларның максаты: туганнар белән якынаю, яшьләрне туганнары белән таныштыру, дуслар булса – кызларын, улларын бер-берсенә күрсәтү булган.



Чириз елгасы аша салынган күпер. 1964 ел




## Боз китү

Авылыбыз уртасыннан Чириз елгасы ага. Элек ул тирәнрәк булган. Балалар боз китүне бик яратып күзәткәннәр. Зурлар да читтә калмаганнар. Боз китү – үзе бер бәйрәм кебек үткән. Авыл халкы матур итеп киенеп, гармуннар уйнатып күпер өстенә җыелган. Егетләр, бала-чага зур бозларга утырып, авылның бер очыннан икенче очына кадәр йөзгәннәр. Боз киткәндәге юка, үтә күренмәле бозны көмеш боз дип атаганнар. Шул көмеш бозны алып кайтып эреткәннәр, чәйгә кайнатканнар. Бу чәйне шифалы дип эчкәннәр. Бозларны озатканда: “Чир-чорларны алып китең, бозлар”, - дип әйтеп калганнар. Күңел ачу һәм бергәләп ял итү бәйрәме булган мондый көн.



Мәктәп музее



Имашев Габдулла хаты. 1942 ел

## Шигърилек

Халкыбызның тагын бер гореф-гадәте, үзенчәлеге - бик шигъри, музыкаль булуы. Моны элекке хатлар да дәлилли. Мәктәп музеенда Бөек Ватан сугышы кырларыннан килгән хатлар саклана. Арасында ирле-хатынлы Закирҗан белән Әминә хатларының эчтәлеге кызыклы (хатларының оригиналы юк, кызганычка каршы).Әминә апа иренә хат яза:

“Одеал ябынасыңмы,
Юрган ябынасыңмы?
Мин сине бик сагындым,
Син дә сагынасыңмы?”

Закирҗан җавап яза:

“Одеал да юк монда,
Юрганы да юк монда.
Көне-төне пуля ява,
Синең кайгы юк монда”.

Үпкәләмәсен дип, соңыннан өсти:

“Сары чәчем, кашсыз нимәм,
Сагындыра башладың”.

(Закирҗан абый сугыштан исән кайта, соңыннан хатыны белән шәһәргә китеп яшиләр).

**Кулланылган чыганаклар:**

1. М.Имашев исемендәге Каенавыл урта мәктәп музее фонды.

2. Авыл халкы истәлекләре

**Автор-төзүче: Луиза Шакманаева**

